# СОВЕТ МӘКТӘБЕ

1918 елның ноябреннән чыга

7 (683) 1990

Татар телендә

ТАТАРСТАН АССР ХАЛЫК МӘГАРИФЕ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ
АЙЛЫК ФӘННИ-ПЕДАГОГИК һӘМ МЕТОДИК ЖУРНАЛЫ



Баш редактор
Ф. Ә. ШӘРИФУЛЛИН.

Редколлегия
М. Ә. ВӘЛИУЛЛИН,
Т. М. ГАЙФУЛЛИНА,
И. Ә. ГАФАРОВ,
М. Г. ГОСМАНОВ,
Р. Ә. ИСЛАМШИН,
М. С. МӘһДИЕВ,
Г. М. МӨХӘММӘТҖАНОВ,
Җ. Г. НИГЪМӘТОВ,
Р. З. СЫРОМОЛОТОВА,
Р. И. ХӘЛИУЛЛИН,
К. З. ХӘМИДУЛЛИНА,
Р. А. ЮСУПОВ,
Ф. М. ЮСУПОВА,
Ф. Ю. ЮСУПОВ,
М. Г. ӘХМӘТҖАНОВ.



КАЗАН


## БУ САНДА


ТАССР ТӨЗЕЛҮГӘ — 70 ЕЛ

**Зыятдинов Ф.**— Ил куәте — икмәктә 3

**Класс җитәкчесенә**
**Җәмилева Г.**— Тәрбия планы кирәкме? 6
**Харисов Т.**— Күмәк иҗади эшләрне оештыру 8
1990/91 уку елына укыту планнары 10

БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘП

Ахунова Г.— Хуш киләсез, нәни дусларыбыз! (Балалар иртәсе) 13
**Алмаев Р.**— I класста хезмәт дәресләре 14
**Юридик практикум** 17

ТУГАН ТЕЛ һӘМ ӘДӘБИЯТ

**Садриев И.**— Морфологияне терәк конспектлар ярдәмендә өйрәнү 18
**Миңнуллин Ф.**— Парлы фигыльләр 22
**Сибгатуллина Ә.**— Кандалый иҗатында хатын-кыз бәхете мәсьәләләре 23
**Поварисов С.**— Шигъри телдәге күркәм гадәтләр 24

**Уйлагыз һәм тәкъдим итегез**
Өзлексез белем бирү концепциясе 26

РУССКИЙ ЯЗЫК И ЛИТЕРАТУРА

**Бакеева М.**— Словесные игры при изучении фонетики, графики и орфографии 27
**Маликов Р.**— В помощь учителю 29
**Шайхутдинова Ф.**— КВН на тему «Люби, цени и знай великий русский язык» 30
**Гарифьянова Р., Ахбарова Г., Скиргайло Т.**— Из опыта конструирования нового учебника VII класса 32

ТӨРЛЕ ФӘННӘР

**Шәфигуллина Д.**— һәркемгә — экологик белем 35
**Галиев В., Мөдәррисов И.**— Алгебра һәм анализ башлангычын укытканда исәпләү эксперименты куллану 36
**Исмәгыйлова Ф.**— Дәреслек белән эшләү 38

# Дəреслек белəн эшлəү

тем һəм тəрбия бирүнең нəтиҗəлелеге турыдан-туры укытучы һəм укучы эшчəнлегенə бəйле. Дəреслек белəн эшлəгəндə укучылар күңелен күтəрердəй һəм шəхси инициативасын үстерердəй эш төрлəрен куллану мөһим. Кайбер темаларның балаларны кызыксындырырлык итеп аңлатылмавы, артык катлаулы булуы да əнə шуны, ягъни иҗади эшлəүне талəп итə.

Укытучы түбəндəге эш төрлəрен файдаланырга мөмкин:

1) теге яки бу тема материалындагы яңалыкны ачыклау. Мəсəлəн, IX класс физика дəреслегенең [1] 11 нче параграфында молекулаларның хəрəкəт итү тизлегенең санча кыйммəте бирелгəн. Бу темадагы төп яңалык — молекулаларның хəрəкəт тизлеген җылылык хəрəкəтенə бəйле күренешлəрнең узу тизлеге белəн чагыштыру;

2) дəреслек материалын иҗади якын килеп карау. Элек билгеле əйберлəрдəге яңалыкны табу.

Мəсəлəн, «Идеаль газның халəт тигезлəмəсе» темасы буенча мөстəкыйль эш болай оештырыла. Башта укучылар VIII класста газлар турында өйрəнгəн белемнəрен укытучы җитəкчелегендə искə төшерəлəр. Аннары IX класс дəреслегендəге материал нигезендə əңгəмə-диспут уздырыла. Дəреслектə идеаль газ турында тулы мəгълүмат бирелгəнме? Тагын нəрсəлəр өстəргə була? һ. б. ш. сораулар тəкъдим итəргə мөмкин

3) дəреслектə бирелгəн теоретик материалның тормыштагы əһəмиятен күрсəтү (Җирле производствода кулланыла торган законнар һəм нəтиҗəлəрне күчереп язу, тормышка бəйле мəсьəлəлəрне күбрəк чишү.)

«Электростатика» темасы (VIII бүлек) буенча уздырылган бер дəрес үрнəген карап үтик. Мөмкинлек булганда, аны радиоательега экскурсия итеп оештырырга мөмкин. Укучылар конденсаторларның радиотехникада кулланылышы белəн танышалар. Аннары экскурсия вакытында үзлəштергəн белемнəрнең кайсы параграфны өйрəнгəндə кирəк булачагын ачыклыйлар;

4) укучыларны актив эшчəнлеккə тарту максатында, аерым темалар буенча иҗади һəм эксперименталь мəсьəлəлəр чишү, фронталь тəҗрибəлəр һəм лаборатор эшлəр уздыру.

Мəсəлəн, чишелгəн мəсьəлəне эксперименталь рəвештə тикшерергə; мəңгелек двигательнең 2-3 проектын төзергə һəм аның мəңге эшли алмавын дəлиллəргə; Г. Н. Плотниковның «Электростатика буенча эксперименталь мəсьəлəлəр» мəкалəсендəге («Физика в школе», 1974, № 1) күнегүлəрне эшлəргə һ. б.;

5) дəреслек материалын фəнни-популяр, публицистик, тарихи чыганаклардан алынган мəгълүматлар белəн баету, шул нигездə укучыларны өстəмə əдəбият белəн эшлəргə өйрəтү. Мəсəлəн, Ом законының математик яктан ничек эшкəртелүе турында («Даими электр тогы» бүлеге) М. И. Блудовның «Беседы по физике» (Просвещение, 1983, II ч.) китабыннан укып белергə мөмкин;

6) укучыларның параграф, бүлек яисə аерым биттəге материалны мөстəкыйль үзлəштерүлəрен оештыру. Укытучы бу эшнең планын, графигын, программасын һ. б. алдан əзерли.

Мəсəлəн, «Сыеклыклар һəм газларның үзара əверелешлəре» бүлеген мондый эзлеклелектə өйрəнергə мөмкин:

а) VI—VII класс физика дəреслегеннəн «Матдəлəрнең агрегат халəте» (90—92 нче параграфлар) бүлеген кабатлау һəм төп төшенчəлəрне аерып алу

б) IX класс физика дəреслегенең 23—25 нче параграфларын уку. Материалны логик яктан тəмамланган кисəклəргə бүлү һəм һəр кисəккə исем кую

в) һəр кисəкнең төп фикерен дəфтəргə язып кую, мəгънəсен ачыкларга тырышу

г) дəреслектə күрсəтелгəн берəр ысул ярдəмендə һаваның чагыштырма дымлылыгын билгелəү өчен тəҗрибə ясау

д) И. И. Шишкин музеена (якындагы истəлекле урынга) бару һəм экспонатларны саклаганда һаваның дымлылыгын ничек һəм ни өчен үлчəүлəрен ачыклау;

е) дəфтəргə экскурсия турында кыскача нəтиҗə язу

ж) 5 нче күнегүнең 5, 7 һəм 9 нчы мəсьəлəлəрен чишү

з) чагыштырма пар ъясалу җылылыгы нəрсəне күрсəтə? Ни өчен басым артканда кайнау температурасы арта? Ни өчен туенган пар басымы күлəмгə бəйле түгел? Һаваның чагыштырма дымлылыгына билгелəмə бирегез. Аны нинди ысуллар белəн билгелəргə мөмкин? дигəн сорауларга җавап əзерлəү;

[1] Классларны иске нумерациягə нигезлəнгəн дəреслеклəр турында сүз бара.

7) дәреслектәге материал нигезендә проблеманы хәл итү уеннары (эшлекле уеннар) оештыру да әһәмиятле. Әлеге уеннар вакытында укучыларга дәреслеккә берничә тапкыр мөрәҗәгать итәргә туры килә. Кроссвордлар, чайнвордлар, төрле кызыклы уеннар төзү өчен, өстәмә әдәбияттан да файдаланалар.

Мәсәлән, «Электромагнитик индукция» темасын өйрәнгәч, «Электромагнитик индукциягә суд» дигән имитацион-процессуаль уен оештырырга мөмкин. Класс ике төркемгә — яклаучылар һәм гаепләүчеләргә бүленә. Судья, гаепләнүче, адвокат һ. б. сайлана. Суд карары «кодекс» (физика дәреслеге) нигезендә чыгарыла.

Укучыларда дәреслек белән эшли белү күнекмәләре кече яшьтән үк булдырыла башлый һәм бу эш өлкән классларда тагын да ныгытыла. Китап уку, укыган материалны анализлау, гомумиләштерү, төп фикерне аерып алу, сорауларга җавап бирү, материалның эчтәлеген эзлекле бәян итү һ. б. күнекмәләр укытуның актив формаларын куллануда зур әһәмияткә ия.

Ф. ИСМӘГЫЙЛОВА,
АДПИ укытучысы.

Совет мәктәбе.- 1990. №.7. С.38-39.

# ОБ ОРГАНИЗАЦИИ РАБОТЫ УЧАЩИХСЯ НАД УЧЕБНИКОМ

Эффективность образования и воспитания в условиях научно-технической революции находится в прямой зависимости от деятельности учителя и учащихся в учебном процессе, и важнейшим инструментом учения для школьников является учебник. Приводимые в учебнике научные сведения служат основой формирования научного мировоззрения учащихся, воспитания у них качеств всесторонне развитой личности, прививая интерес к данному предмету, стимулируя желание учащегося к самостоятельному приобретению знаний. Школьный учебник служит и методическим ориентиром для учителя, определяя последовательность введения понятий, глубину их раскрытия, рационально распределяя время между отдельными частями вводимого учебного материала.

Однако приведенных выше функций недостаточно для воспитания всесторонне развитой личности, подготовки ее к жизни, к выбору профессии. Рассмотрим с этой точки зрения возможности учебника по физике, науке, непосредственно связанной с жизнью. В силу этого возникает необходимость разработки специальной методической системы организации работы учащихся над учебником, работы активной, результативной, сочетающей умственную и эмоциональную деятельности прусматривающую не только развитие мышления, но и чувств, воли учащихся. Это означает, что при работе над учебником должен соблюдаться принцип: конкретную деятельность всегда связывать с такими формами работы, которые вызывали бы эмоциональный подьем, личную инициативу учащихся. Так, некоторая сухость и академичность изложения материала в учебнике для IX класса, излишняя сложность теоретических выкладок, особенно по теме "Основы молекулярно-кинетической теории", неполнота целевой установки заставляют учи-